


Томән татарларынын «Янарыш» сайтында Диләфрvз Фәхретдинованын «Мордовиядә халык гадел, кунакчыл» дигән язмасы чыккан.
1-2 июль коннәрендә Мордовия Республикасынын Ләмберә районы, Аксюн авылында XII Ботенроссия авыл Сабан туе уздырылды. Сабантуйга Россиянен 30дан артык регионыннан, шулай ук Мордовиянен барлык районнарыннан кунаклар килде. Ачу тантанасында , Мордовия башлыгы Артем Здунов, Татарстан Республикасы президенты Ростәм Миннеханов катнаштылар.      Томән олкәсеннән дә шушы авыл Сабан туена делегация барды. Без делегация әгъзасы - Ялутор районы, Аслана татар мәдәният vзәге директоры Илчан Хоснетдиновтан Сабан туе турында тәэсирен сорадык.
«Томән олкәсе делегациясен Бо-тендонья татар конгрессынын Томән олкәсе вәкиллеге житәкчесе ярдәмчесе Зилә Юсупова житәкләде. Юл чыгымнарын «НПО Арктикпромизыскание» оешмасы генераль директоры Реваль Хоснетдинов тvләде. Тубыл шәһәренен себер-татар мәдәният vзәгеннән жырчы Хәсән Хучашев, «Ак калфак» олкә татар хатын-кызлар ижтимагый оешмасы әгъзалары Рузилә Илчегулова, Лилия Габдуллина, Римма Вәлиева бардык.
Безгә куратор Алексей Бабаевны билгеләделәр. Ул безне ботен жиргә йортте. Кунакханәдә яшәдек, Саранск шәһәрендә музейларга кердек.
Мона кадәр Мордовиядә булганым юк иде. Аксюн авылында борынгы ойләр янына яналары тозелгән. Ботен жирдә искиткеч чисталык, бигрәк матур яклар.
Сабантуйда дvрт сәхнә эшләде, бер-сендә Хәсән Хучашев белән чыгышлар ясадык. Халык гади, кунакчыл, безне зур алкышлар белән каршы алды.
Мәйданнарда спортчылар, сәнгать осталары ярышты, ат чабышлары vткәрелде, милләттәшләребез ихлас кvнел ачты. Раил Нургалиев исемле егет абсолют батыр калды. «Лада Гранта» ачкычын Ботендонья татар конгрессы Башкарма комитеты житәкчесе Данис Шакиров тапшырды. Моннан тыш егеткә тәкә һәм Сочи курортына путевка бирделәр.
Сабантуйдан гажәеп яхшы тәэсирләр белән кайттым: яна кешеләр белән таныштым, гvзәл жирләр кvрдем, мил-ләтебезнен бай тарихы, мәдәнияте тагын бер тапкыр vзенә жәлеп итте, сокландырды. Оештыручыларга зур рәхмәт», - дип сойләде Илчан Миннегалим улы.